ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 504-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 504-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 ноябре
№ 2251-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтәкүләменнән кимрәк булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 пунктта «җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтәкүләменнән кимрәк булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән хроник бөер җитешсезлеге һәм онкология авырулары белән интегүче затларга медицина оешмаларына дәвалану урынына бару һәм кире яшәү урынына кайту чыгымнарын компенсацияләү каралган. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы мондый гражданнарның гаиләсенең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган очракта бирелә.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты белән күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын алу шартларыннан мохтаҗлык критериен алып ташлау күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү атарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарына компенсацияләр бирү, онкология авырулары белән авыручы, махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтә торган затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларындагы дәвалану урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнарын компенсацияләү тәртибе турында» 2013 елның 9 октябрендәге 743 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән хроник бөер җитешсезлеге һәм онкология авырулары белән интегүче затларга медицина оешмаларына дәвалану урынына бару һәм кире яшәү урынына кайту чыгымнарын компенсацияләү каралган, әгәр аларның җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булса.

Татарстан Республикасы бюджетында ел саен хроник бөер җитешсезлеге һәм онкология авырулары белән интегүче кешеләргә дәвалану урынына һәм яшәү урынына транспортта шәһәр арасына йөрү чыгымнарын компенсацияләүгә акчалар карала.

Социаль ярдәм чарасын алуның күрсәтелгән шартын исәпкә алмаганда, шулай ук барлык гражданнарга (шул исәптән бер торак пункт кысаларында) юл йөрү чыгымнарын компенсацияләү очрагында, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына өстәмә ихтыяҗ күләме ел саен 93 208,1 мең сум күләмендә бәяләнә, шул исәптән:

амбулатор гемодиализ үткән урынга бару һәм кире кайту чыгымнарын компенсацияләүгә – 29 083,5 мең сум;

онкология авыруларыннан интегүче затларга юл йөрү чыгымнарын компенсацияләүгә – 64 124,6 мең сум.